ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 май 2026 ел. № 4548

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына урнашучы зат һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында нигезләмәне раслау турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 281.1 статьясы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына урнашучы зат һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында нигезләмәне кушымтада караралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче граждан, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында нигезләмәне, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесенең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында www.nabchelny.ru урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 10 августындагы 5303 номерлы Карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 14 маендагы
4548 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына урнашучы зат һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында
нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына урнашучы зат һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук үзенең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар (алга таба – керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар) бирү тәртибен билгели.

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына урнашучы затның (алга таба - муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына урнашучы зат) һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесенең (алга таба - муниципаль учреждение җитәкчесе) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар бирү бурычы аларга Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 281.1 статьясы нигезендә йөкләнә.

3. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына урнашучы зат һәм муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе Президентының рәсми сайтында урнаштырылган, аңа сылтама шулай ук дәүләт хезмәте өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштырыла торган «Справки БК» махсус программа тәэминатыннан файдаланып тутырылган белешмә формасы буенча тапшырыла.

4. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына урнашучы зат тапшыра:

1) муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә урнашу өчен документлар тапшыру елыннан алдагы календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган үз керемнәре (элеккеге эш урыны яки сайлаган вазыйфасын биләү урыны буенча алынган керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне һәм башка түләүләрне кертеп) турында мәгълүматларны, муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә урнашу өчен документлар тапшыру аеннан алдагы айның беренче числосына (хисап датасына) кадәр аның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм үзенең мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны;

2) муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә урнашу өчен документлар тапшыру елыннан алдагы календарь ел өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган керемнәре (хезмәт хакын,

пенсияләрне, пособиеләрне һәм башка түләүләрне кертеп) турында мәгълүматларны, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә урнашу өчен документлар тапшыру аеннан алдагы айның беренче числосына (хисап датасына) кадәр аларның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны.

5. Муниципаль учреждение җитәкчесе «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында мәгълүматлар бирү өчен нигезләр барлыкка килгән очракта — мондый нигезләр барлыкка килгән елдан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшыра:

1) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында мәгълүматлар бирү өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр (хисап чорында) барлык чыганаклардан алынган үз керемнәре (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне һәм башка түләүләрне дә кертеп) турында мәгълүматларны, хисап чоры ахырына торышы буенча аның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны;

2) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында мәгълүматлар бирү өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр (хисап чорында) хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган керемнәре (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне һәм башка түләүләрне кертеп) турында мәгълүматларны, хисап чоры ахырына торышы буенча аларның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны.

6. Әлеге нигезләмәнең 4 һәм 5 пунктларында каралган мәгълүматлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасарлары тарафыннан билгеләнә торган әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затларга тапшырыла.

7. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына урнашучы зат, муниципаль учреждение җитәкчесе керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында үзләре тарафыннан бирелгән мәгълүматларда нинди дә булса мәгълүматлар чагылдырылмаган яки тулысынча чагылдырылмаган яисә хаталар булган очракта, алар әлеге нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә төгәллек кертелгән мәгълүматларны бирергә хокуклы.

Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына урнашучы зат төгәллек кертелгән мәгълүматларны әлеге нигезләмәнең 4 пункты нигезендә мәгълүматлар бирелгән көннән башлап бер ай эчендә бирергә мөмкин.

Муниципаль учреждение җитәкчесе төгәллек кертелгән мәгълүматларны әлеге нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә бирергә мөмкин.

8. Әлеге нигезләмә нигезендә муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына урнашучы зат, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан бирелә торган керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар, әгәр федераль закон белән алар дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларга кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы белешмәләр булып тора.

9. Әлеге нигезләмә нигезендә муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына урнашучы зат, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан бирелә торган керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында

мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү, законнар нигезендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының тармак (функциональ) органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

10. Әлеге нигезләмә нигезендә муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына урнашучы зат һәм муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан бирелә торган керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны җыю һәм эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затлар, аларны Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда таратуда яки файдалануда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

11. Әлеге нигезләмә нигезендә бирелгән керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар һәм әлеге мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат муниципаль учреждение җитәкчесенең шәхси делосына теркәлә.

12. Әлеге нигезләмә нигезендә керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар биргән муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына урнашучы зат муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына билгеләнмәсә, күрсәтелгән мәгълүматлар аның язмача гаризасы буенча башка документлар белән бергә кире кайтарыла, ә язмача гариза булмаганда, юкка чыгарылырга тиеш.

13. Керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар бирмәгән яки белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән очракта, муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына урнашучы зат муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына билгеләнә алмый.

14. Муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирмәү яисә тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүматлар бирү, эш бирүче ягыннан аңа карата ышаныч югалу сәбәпле, төзелгән хезмәт шартнамәсен өзү (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 статьясындагы 1 өлешенең 7.1 пункты) яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар җаваплылыкның башка төрләрен куллану өчен нигез булып тора.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева